Салават Рәхматулла
Космонавт булам!
*Балалар өчен шигырьләр, табышмаклар, шарадалар*
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Р95

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*
**Рәхмәтулла, С.И.**

Космонавт булам! : балалар өчен шигырьләр, табышмаклар, шарадалар / Салават Рәхмәтулла ; кереш сүз авт. Л.Шәех. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 95 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-01799-2

Әлеге җыентыкта Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре Салават Рәхмәтулланың балалар өчен язылган шигырьләре, табышмаклары һәм шарадалары урын алды.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2 Рос=Тат)-5
ISBN 978-5-298-01799-2
© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Рәхмәтулла С.И., 2010

## Үзебезнең Салават абый!

Салават абый Рәхмәтулланы мин берничә ел беләм инде. Гомер узган саен, ул миңа тагын да якынрак булып тоела, тагын да үз кешегә әйләнә бара. Ни өченме? Чөнки ул – чын мәгънәсендә шагыйрь, зур шагыйрь, көчле шагыйрь. Беренче очрашу вакытында ук аның шигырьләре күңелемнең иң нечкә кылларын тибрәтте, йөрәгемә сары май булып ятты. Хәзер төгәлрәк сөйлим... 2006 елның май аенда без, Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары, Башкорт дәүләт университетының «Акчарлаклар» һәм «Шоңкар» әдәби түгәрәкләре чакыруы буенча Уфага бардык. Дүрт көнлек программада Стәрлетамак шәһәренә сәяхәт каралган иде. Салават абый белән без шунда очраштык та инде.
Казаннан килгән яшь каләм ияләре хөрмәтенә Стәрлетамак дәүләт педагогия академиясенең актлар залында студентлар белән очрашу оештырдылар. Безнең чыгышлар Башкортстанда яшәүче дусларыбыз иҗаты белән аралашып барды. Иң ахырдан сәхнәгә Салават абый күтәрелде. Күп тә узмады, залга берсеннән-берсе ихлас, мәгънәле, тирән фәлсәфи шигырьләр ява башлады. Без барыбыз да, йотлыгып, өнсез калып, шагыйрьне тыңладык... Бигрәк тә аның Болдино турындагы шигыре хәтергә сеңеп калган. Бөек рус шагыйре А.С. Пушкинга Болдино авылы никадәр якын булса, С.Рәхмәтуллага да туган авылы – Башкортстанның Авыргазы районындагы Солтанморат авылы шулай кадерле. Хәер, әйтсәм әйтим инде, татар халкының күренекле классик язучысы Галимҗан Ибраһимов та, Салават Рәхмәтулла да – Солтанморат егетләре!
Салават абый – көчле лирик шагыйрь. Юморы берара мөлаем, берара усал һәм көчле нәтиҗәләргә алып чыга. Ә балалар өчен язылган шигырьләре якты, самими, кызыклы, заманча. Иң мөһиме – саф, балаларча! «Шуклык бәласе» дигән дүртьюллык шигырен генә алыйк:

– Малаең шук! – ди күрше карт,
Зарлана әтиемә.
Әти... кычыткannар йолка:
– Рәхмәт, – ди, – әйтүеңә...

Артык сүзләр кирәкми, барысы да аңлашыла. Үзе кыска, үзе мәгънәле, үзе тормышчан һәм тәрбияви. Шигырьнең «тел төбе»ндә нәрсә ятканын һәркем аңлый.

Салават Рәхмәтулла баланы, аның кызыксынуын үз артыннан ияртеп алып бара һәм шигырен һич көтелмәгәнчә тәмамлап куя. Бу исә интрига тудыра. Балага нәкъ менә шундый әсәрләр ошый да инде. Китаптагы «Нигезле дәлил», «Укырга өйрәнәбез», «Келәт», «Урманда» һ.б. шигырьләрне укып карагыз әле. Үзегез дә моңа инанырсыз.
Шагыйрь балаларча фикерли белә. «Барометр» дип аталган шигырен алыйк. Бер карасаң, дәү әни белән кечкенә баланың дөньяга карашы, уйлары аерыла. Дәү әни гореф-гадәтләр, ышану-хорафатлар буенча, үзен чолгап алган табигать, анда яшәүче тере җан ияләре аша фикер йөртә. Мәче мичкә кереп ятса, димәк, көн суыта, әгәр ул идәндә йокласа, җылы һава киләчәк! Ә оның заманча уйлый. Яңа гасыр кешесе күбрәк төрле приборлар, кешелекнең зур алгарышын тәшкил иткән җайланмалар аша фикер йөртә бит. Ул шуның белән табигатьтән ераклаша да. Ә бу шигырьдәге бала «алтын урталык»ны таба. Аныңча, мәче гади мәче генә түгел, ә һава торышын алдан фаразларга мөмкинлек бирә торган «тере прибор» да:

Иртәгә көн суык була –
Өеңдә генә утыр:
Мәче мичкә кереп китте,
Мәче ул – барометр!

Салават Рәхмәтулла үзенең шигырьләрендә йорт хайваннарын, йорт кошларын, киекләрне («Урамнан үттем атта», «Күркә», «Куркак куян»); табигать күренешләрен («Карлар эри...», «Яшенле яңгырда», «Яз кояшы»); татар гаиләсен, анда барган кызыклы һәм тәрбияви ситуацияләрне («Дәү әнием төшләр күргән», «Солдат», «Телевизор карыйбыз»); бала күңелен («Космонавт булам!», «Үзем дә белеп торам!», «Капкачы») сурәтли. Шагыйрь баланы өлкәннәргә хөрмәт белән карарга, табигатькә сак мөнәсәбәттә булырга, хезмәтне сөяргә өйрәтә. Үзенчәлекле табышмаклары, шарадалары, сүз уйнатулары аша сабыйларны зирәклектә сыный.
...Әйе, Салават абый Рәхмәтулла белән без тагын бер мәртәбә аның балалар шигырьләре аша очраштык. Алла боерса, киләчәктә күрешүләр күп булсын. Һәрхәлдә мин шулай дип телим. Бу китапны кулына алган һәркем өчен Салават абыйның үз кешегә әйләнәчәгенә чын күңелемнән ышанам!
*Ленар Шәех*

# ШИГЫРЬЛӘР

## Космонавт булам!

...Бертуктаусыз: көнен-төнен,
Иртән дә, кичен дә мин
Йолдызларга табан очам,
Зур кораб эчендә мин.

Марска да төшәсе бар...
Тик... Сагындым өемне.
Әниемне дә сагындым,
Сагындым әтиемне.

Акбайсыз, песисез хәтта
Җиһанда да күңелсез.
Энем елыйдыр...
Дәү әни
Ничек чәй эчәр минсез?

Кайчан өйгә кайтам инде?
Сагындым, бетте түзем...

Корабны туктатып,
Җиргә –
Кирегә бордым үзен...

...Уянып китсәм – кайтканмын:
Өебез эчендә мин...
Космонавт булам!
Әлегә
Космонавт – төшемдә мин.

**Барометр***

«Көн суытыр», – ди дәү әни,
Мәче мичкә кердисә.
«Көн җылыныр», – ди, идәндә
Йоклап ятканын күрсә.

Иртәгә көн суык була –
Өеңдә генә утыр:
Мәче мичкә кереп китте,
Мәче ул – барометр!

* Барометр – атмосфера басымын үлчи торган прибор.

**Куркак куян**

Аюдан да куркасың,
Бүредән дә куркасың.
Көпә-көндез ялан буйлап
Йөрүдән дә куркасың.

Төлкедән дә куркасың,
Еланнан да куркасың.
Керт-керт яфрак өзеп торган
Боланнан да куркасың.

Хәтта миннән дә куркасың.
Нинди эшләр кылдың син?
Курыкма син! Курыкканга
«Куркак куян» булдың син.

**Битен юды**

«Мияу-мияу-мыр, – дидем, –

Мияубикә, тор, – дидем, –
Тор, йокыңны ку, – дидем, –
Ку – битеңне ю», – дидем.

Икмәк куйдым, ит куйдым,
Тәлинкәгә сөт койдым:
«Аша, – дидем, – туй, – дидем, –
Башта битең ю!» – дидем.

...Ашап-эчеп туйды ул,
Шуннан... битен юды ул.

**Серле пычкы,**
**тылсымлы балта...**

Урамга чыктым – суык
Өемә кертте куып...

Әти әйтте: «Чыгабыз,
Суыкны без куабыз.

Алырбыз котын, – диде, –
Пычкыга тотын!» – диде...

Икәү утын кисәбез,
Изүләрне чишәбез.

Сез балтага карагыз:
Тирләп утын ярабыз!

**Нигезле дәлил**

Иртәнге аш: абый, сөеп,
Аркамнан сыйпый-коча:
– Энем үскән, – ди, – бүген дә
Ашый ул... юынмыйча.

– Юыныр идем дә, – дидем, –
Сәбәбе түгел миндә:
Юынгыч суын юынып
Бетергәнсез бүген дә...

**Дәү әнием төшләр күргән**

Дәү әни бүген төн буе

Тыныч йоклый алмаган:
«Төн буе төшләр күрдем», – ди,
Күрмәгәне калмаган.

«Имеш, мин урманда йөрим –
Килеп чыкты елан, – ди, –
Оныгыңның исеме кем?
Танышмакчы булам, – ди. –

Еланнан котылдым, алда
Зур бүре утыра, – ди, –
Авылың кайда, оныгың
Кайсы йортта тора? – ди. –

Бүредән дә киттем! Хәзер
Алдымда бер үгез, – ди. –
Исеме кирәкми миңа,
Сез үзен бирегез! – ди...»

Бүре, үгез, хәтта елан! –
Күрмәгәне калмаган:
Дәү әнием, мине саклап,
Тыныч йоклый алмаган...

Ә елан, бүре, үгезнең
Белдем ник үч тотканын:
Дәү әнигә тыныч йокы
Теләргә онытканмын...

**Зыя вак балыклар җыя**

Дуслары белән елгада
Балык каптыра Зыя:
Зурларын кире җибәрә,
Вакларын гына җыя.

«Вакларын, – ди, – үзем карап
Үстерергә бар уем:
Туган көнгә бүләк итте
Әтием аквариум!»

**Укырга өйрәнәбез**

Хәреф өйрәнәм, апамнан
Әлифба сорап алып.

«Мә-мә...» – дип, кулларын суза
Энем дә, күреп калып.

Сиңа бирсәм, үзем ничек
Укырга өйрәнермен?
«Әлифба үземә кирәк,
Мә, гәзит бирәм!» – димен.

Сүзләр укыйм! Энем уйный
Гәзитне кыштырдатып.
Әтием: «Әнә, күр, энең
Укый, – ди, – шытырдатып...»

**Яшенле яңгырда**

Яшен яшьни,
Күкләр күкри...
Дәү әни: «Йа Хода, – ди, –
Су тулы мичкәләр белән
Күктән атлар уза», – ди.

Күкләр күкри –
Атлар, өркеп,
Дуларга керешкәнме?
Яңгыр коя – мичкәләрен
Яшен атып тишкәнме?..

**Мультик**

Куянны куа бүре,
Бүредән кача куян:
Әллә эшләгәнме куян
Бүрегә берәр зыян?

Ашыйсы килгән бүренең,
Шуңа куа: «Тотам!» – дип.
Авызын зу-у-ур ачып чаба:
«Тотам, тоткач – йотам!» – дип...

Куянкайның хәле бетә:
Аһ, тотыла... тотыла...
...Бүре тотар-йотар иде,
Мультик... бетеп котыла!..

**Солдат**

Абыем минем
Солдаттан кайтты! –
Күңелдә – шатлык,
Өйдә ямь артты!

– Ки фуражка, – ди, –
Каеш бу әле.
Нәни солдатка
Охшап куй әле!..

Агач автомат
Иңемә астым
Һәм тизрәк көзге
Алдына бастым.

Көзгедән солдат
Елмаеп тора:
– Абыем, бу – мин,
Мин – солдат! Ур-р-ра!

Капкадан чыктым,
Урамнан үттем,
Каз бәбкәләрен
Сакларга киттем!

**Яз кояшы**

«Сау бул!» – дип озатып калдык,
Кул болгап калдык кышка.
«Яз алып килдем!» – дип,
Кояш
Чакыра безне тышка.

...Сыерчыклар оя сайлый –
Бик сагынып кайтканнар.
Эт белән песи
Болдырга
Сузылып ук ятканнар.

Кәҗә дә чыккан,
Капканы
Мөгезе белән ачып.
Тавыклар җылынып тора,
Сыер өстенә басып...

«Кояш яз алып килде!» – дип
Җырлый җир, җырлый күкләр.
Гөрли-гөрли,
Елгаларга
Йөгерә гөрләвекләр!..

**Календарь**

Эленеп тора календарь,
Бер бите бер көн аның.
Һәр көн иртән ертабыз без
Бер генә битен аның.

Икешәр бит ертсаң икән –
Көннәр тиз үтәр иде.
Мәктәпкә бара торган көн
Тиз килеп җитәр иде.

...Календарь битләре кими:
Калдырып читен генә,
Ашыга-ашыга ертабыз
Көн дә бер битен генә.

**Әтәч**

– Әтәчегез еш кытаклый,
Ничек армый-талмый ул?
– Тавыкларга кытаклаша!
Ә үзе хәтта бер генә
Йомырка да салмый ул...

**Болыннарда, аланнарда...**

1

...Җиләккә бардык абыем,
Апам – өчәү, күмәкләп.
Болыннарда, аланнарда
Җиләк җыйдык чиләкләп.

«Яңгыр болытлары килә! –
Апам алды җитәкләп, –
Бик кыздырды: яңгыр явар,
Яуса, явар чиләкләп...»

...Кайттык. Әни чәй кайнаткан! –
Баллап, майлап, җиләкләп,

Өреп-өреп чәй эчәбез,
Яңгыр коя чиләкләп...

2

...Әни белән җиләктә без,
Аптырап карыйм менә:
Әниемнең тырысында
Гел эре җиләк кенә!

Минекеләр – вак...
Ник әле
Аптырап шаккатканмын?! –
Мин гел вагын җыйганмын бит,
Эресен... гел капканмын...

**Әнием уңган!**

Урынымны җыештырам,
Күлмәкне киям үзем.
Әнием: «Кул арасына
Керә, – ди, – минем кызым».

Идәннәрне юып алам,
Юамын керләрне дә.
Һәр көн иртән сулар сибеп
Үстерәм гөлләрне дә.

Иртән торуыма һаман
Әллә күпме эш көтә.
Ярый әле әни уңган,
Әнием ярдәм итә!
**Карлар эри...**

Өс киемнәрен салабыз...
Күлмәкчән калып кына,
Тирләп-пешеп, кар көрибез,
Көрәкләр алып кына.

Дәү әти әйтә: «Көрәсәң,
Язын тиз эри карлар».
Ихаталарда, урамда
Казлар су коеналар.

Карлар эри, сулар ага,
Бозларны тишә-тишә.

Кыектагы карлар, эреп,
Үзләре шуып төшә.

**Өй рәсеме**

Өй рәсеме ясап куйдым,
Ишек-тәрәзләр уйдым.

Койма белән әйләндерәм –
Өйнең алды яшел чирәм.

– Морҗалы була өйләр,
Синең – морҗасыз, – диләр.

– Хата түгел һич, – дидем, –
Сүтелгән ич мич, – дидем.

– Мичсез ничек көн итәсе?
– Бар бит газ плитәсе!

**Серле чәйнек**

Әти каладан бер чәйнек
Алып кайтты.
Кисәтте:
«Күзәтмәгез – кайнаганын
Үзе әйтә!» – дип әйтте.

Чәйнек – газда. Онытканмын...
Әни дә чыга-керә...
«Чәегез кайный!» дип,
Чәйнек
Сызгырып тавыш бирә!..

**Кулчатыр**

Юеш җилләр офыклардан
Болытлар ташып йөри.
«Тагын яумаса...» – диеп, Нур
Җилкәсен кашып йөри.

Кулчатырын тотып чыккан:
«Дөрес сөйлим, танмыйм, – ди, –
Яңгыр көн буе яуса да,
Тамчы да чыланмыйм!» – ди.

Җилләр болытларны җыйды:
Яшен яшьни, күк күкри.
Кулчатырлы Нур көн буе
Яңгырны күтеп йөри...

**Күркә**

– Ник күркә кабара? – дидем...
Әйтте апам Гөлүсә:
– Кызыл күлмәгең киеп чык,
Бик тә беләсең килсә...

**Шуклык бәласе**

– Малаең шук! – ди күрше карт,
Зарлана әтиемә.
Әти... кычытканнар йолка:
– Рәхмәт, – ди, – әйтүеңә...

**Булыштым!**

Тавыкларга җим сибештем,
Күлгә казлар куыштым.
Күлдән су алып кайтыштым,
Аннан керләр уыштым.

Керләрне бауга элештем,
Аннан идән юыштым.
Аш та пешерештем әле,
Самавыр да куештым.

Әни мактап бетералмый,
Булыштым шул, булыштым:
Әнием эшләгән чакта
Еламаска тырыштым!

**Капка ачучы**

– Көтү кайта, ач капкаңны,
Бикле бит капка келәң!
– Кәҗә, алдан кайтып, аны
Ача мөгезе белән...

**Мәче — нәрсә? Песи — ни?..**

Мәчене – песи, песине
Мәче дип атамачы:
Песи – ана мәче була,
Ә мәче – ата мәче!..

**Яңгыр**

Яңгыр ява...
Әни әйтә:
– Чык, чиләкләр куябыз:
Өй кыегы буйлап аккан
Яңгыр суын җыябыз.

Әтиең эштән кайтуга,
Мунча ягып куярбыз.
Йомшак яңгыр суы белән
Чәчләреңне юарбыз.

...Узды яңгыр:
Суын җыйдык –
Буш савытлар калмады.
Чәчләр – лычма, ә күлмәкләр –
Сыгып-сыгып алмалы...

**Искәндәр**

Җәй буена түтәлләргә
Сулар сипте Искәндәр.
Һәр көнне чебешләр куды,
Арып бетте Искәндәр.

– Бакчага чебешләр хәзер
Нигә керми, Искәндәр?
– Рәшәткәләр арасына
Сыймыйлар бит – үскәннәр!

**Зур курчак**

Урамда уйнап йөрибез...
Дусларның-малайларның
Апалары, абыйлары,
Энеләре, сеңелләре
Барсының бар аларның...

Минем генә беркемем юк...
Сеңлем белән энем дә,
Абыем белән апам да
Булсын иде минем дә!

Әниемнең, әтиемнең
Мин бердәнбере генә:
«Мин – бердәнберегез!» – диеп
Йөрдем гел эре генә.

Бердәнберебез дип, миңа
Әллә ниләр алдылар.
«Ник мин бердәнбер соң?» – дигәч,
Аптырашта калдылар...

Әти: «Тагы ни кирәк?» – ди...
Әни: «Ни җитми моңа?!»
«Эне йә сеңел алыгыз,
«Абый!» дип әйтсен миңа!..»

«Акча булгач та...» – ди әни,
Әтием дәшми тора.
...Зур курчак алдылар. Курчак
«Абый!» дип авыз ера...

**Телевизор карыйбыз**

Әти, әни, мин – өчәүләп
Телевизор карыйбыз.
Телевизор караганда,
Өчәүләшеп арыйбыз.

Беренче каналда һаман
Мультфильм була көн дә.
Икенче каналда – концерт,
Кино – өченчесендә.

Әтигә гел кино кирәк,
Әнигә – концерт кына.
Нигә миңа кино, концерт? –
Булсын мультфильм гына!

Телевизорыбыз – берәү,
Өчәүләшеп карыйбыз:
Кыза-кыза, каналларны

Күчерәбез, арыйбыз...

Әнием гел концерт карый!
Әти – кино, мин мультфильм
Караган көннәр сирәк...
Безгә... Безгә өч бүлмә һәм...
Өч телевизор кирәк!..

**«А-а-а...»**

...Чирләдем.
Врач апага
Әнием алып барды:
Врач апа дәвалый ул
Барча авыруларны.

«Мә дарулар, савыгырсың,
Шуларны эчә-эчә».
Белми дигәндер: бер «А»ны
Әйттерде әллә ничә.

Нигә гел «А»ны сорады,
«Ә», «Б» лар ярамады?
Эх, укый да белә идем,
Укытып карамады...

**Чүкеч**

Чүкеч тоттырды дәү әти
(Ял итә бүген – өйдә):
«Бик кирәкле һөнәр ул, – ди, –
Кадак кага белү дә!»

Вак кадаклар да бирде ул:
«Менә такта, как!» – диде.
Кадакка дип суккан идем,
Чүкеч... бармакка тиде.

Чүкечем кадакка тисә,
Тимер тавышы чыга.
Кадак кагарга өйрәнәм,
Бармакка суга-суга.

**Үзем дә белеп торам!**

«Ишекне ябып йөрегез,
Ачык кала күрмәсен.
Өй эче гел җылы торсын,
Тыштан суык кермәсен!..»

Әни безгә гел шулай ди.
«Җәй үтте, хәзер көз, – ди, –
Суык тидерә күрмәгез,
Киенеп йөрегез!» – ди...

Җәй ашыгып китеп барды –
Үзем дә белеп торам:
Ишеге ачык калгандыр,
Шуңа суыктыр урам...

**Келәт**

...Туп алып чыктым – ишеген
Ябарга онытылган.
Келәттә – ашлык!..
Келәткә...
Тавыклар кереп тулган...

– Син ачтыңмы? – диләр миңа...
Абый күз кыса – күргән:
– Әтәч
Тавыклары белән
Келәткә басып кергән!..

**Капкачы**

Зур малайлар мәйданчыкта
Хоккей уйныйлар көн дә.
«Мине дә уйнатыгыз!» дип
Үтендем мин бүген дә.

«Бүген уйнатырлар» диеп
Торсам да көтеп кенә,
Уйнатмадылар –
Куйдылар
Капкачы итеп кенә.

Үпкәләсәм дә,
Ачуны
Беркемгә белгертмәдем.

Сер бирмәдем:
Бер алка да
Капкага керттермәдем!

**Чәчәкле болында**

Күктә – сабан тургайлары,
Җыр гына болын юлы.
Чәчәкләр арасы – җиләк,
Чәчәкләр – болын тулы!

Кулларыбызда – тырыслар,
Йөрмәдек һич эзләнеп:
Бер чәчәк тә өзмәдек без,
Җиләк җыйдык тезләнеп.

**Абыем — укучы!**

Абыем мәктәптә укый:
Эше хәзер муеннан...
Шуңа үзем гел иртәрәк
Уянам абыемнан.

Көн дә аны уятам мин:
Торсын – йоклап ятмасын.
Юынсын да, ашасын да,
«Туган тел»не ятласын!

Шакмаклы зәңгәр дәфтәрен
Алсын да сумкасыннан,
Мәсьәләләрен эшләсен
Математикасыннан!

Каләмнәрен очлап бирәм,
Баргач сурәт буярга.
Өйрәтәм: «Алмага – кызыл,
Яшел каләм – кыярга!..»

Тырышсын,
гел «бишле» алсын,
«Өчле»гә укыганчы...
Абыем мәктәпкә киткәч,
Йоклыйм үзем туйганчы!..

**Урманда**

Бүре бар, ди, урманда,
Болан бар, ди, урманда.
Аю бар, ди, урманда,
Елан бар, ди, урманда...

Йөгереп күбәләкләр куам,
Җиләк җыям урманда.
Курыкмыйм мин урманда,
Әти белән булганда!

**Витаминлы кыярлар**

Әни түтәлдән кыярлар
Алып керде дә: «Мин, – ди, –
Эшкә китәм, әрчегез дә
Ашагыз витамин!» – ди.

Үзем юдым, аннан үзем
Әрчедем кыярларны.
Абый әйтә: «И энем, ник
Әрчедең син аларны?

Кыярның витаминнары
Аның кабыкларында».
Абый врачлыкка укый,
Белә шул ул барын да...

Мине мактап, кыярларны
Ашады абыем да.
Ә мин... кабыгын ашадым:
Витамин – кабыгында!..

**Самавыр**

Өстәлдә икмәк, сөт тора,
Бал тора, каймак тора –
Чәй эчәбез: җиз самавыр,
Пар бөркеп, кайнап тора.

Абый (үзе – авыз ера!):
– Карагыз, карагыз, – ди, –
Самавыр пар белән эшли,
Әйтерсең паровоз! – ди...

**Велосипедым**

Велосипед алды әти,
Биш яшем белән котлап.
Әйтте: «Урамда йөргәндә,
Кагыйдә белү мотлак*».

Велосипедым капкадан
Чыгарга гына тора:
Өч тәгәрмәчле булса да,
Егарга гына тора...

Әтием: «Урамнар тулы
Машиналар, улым, – ди. –
Кагыйдәне өй янында
Өйрәтергә булдым», – ди.

«Кызыл төс!» дисә, тукталам,
«Сары!» дисә, көтәм мин.
«Яшел!» дигән сүзне көтәм,
«Яшел!» дигәч, китәм мин.

Һәм тагын капкага карап
Юл алам мин, юл алам...
«Кызыл төс!» дисә әтием,
Тагын тукталып калам.

«Кызыл төс!» – чыгып китәргә
«Яшел төс!» – көтеп торам...
«Ашыкмый тор, – ди дәү әти, –
Капкадан чыксаң – урам!..»

**Пляжда**

– Иртән пляжга барыйк, – дип
Әйтте абый кичкырын.
– Нәрсә ул пляж?..
– Пляж ул...
Су керә торган урын!..

– Пляжга! – дидек әнигә,
Иртән чыгып киттек без:
Бара-бара, бара-бара,
Ерак күлгә җиттек без.

– Бу – Ерак күл!..
Абый:
– Дөрес,
Үзебезнең күл, – диде. –
Монда шәһәрләрдән килеп
Су керәләр, бел! – диде.

– Бу пляж буламы инде?
– Ни була соң, уйла, – ди. –
Яр буенда комы бармы?
Булса, пляж була! – ди...

Көн буе су коендык без,
Комда кызынып яттык...
– Кайда йөрдегез? – ди әти.
– Пляжда булып кайттык!..

**Сукыр тычкан**

Бар дөньясы – җир астында:
Туган иле, өе дә.
Караңгыда яши тычкан,
Яши сукыр көе дә.

Бәрелә дә, сугыла да,
Абына да, егыла да,
Дөнья куа – чаба ул:
Ашарын, эчәрен – барын
Сукыр килеш таба ул.

Кайгыларга кайгыра ул,
Шатлыкларга сөенә.
Хәсрәткә дә, михнәткә дә
Түзә сукыр көенә.

Берни күрми җир астында,
Тик... хата бар кечкенә:
Караңгыда ни күрсен ул? –
Караңгыда аңа күзләр
Кирәк түгел һич кенә!..

**Мунча түбәсен ябабыз**

Абый биргән такталарны

Әти белән кагабыз.
Өчәүләп мунча түбәсен
Ябабыз без – карагыз!

Дуслар килгән: ник, янәсе,
Бүген юк уенда мин?
– Әй, эзләмәгез, мин монда,
Мунча кыегында мин!

**Укчы**

Уйнап йөрим,
Кулларымда
Җәя белән ук.
Тик бер җан иясенә дә
Төзәп аткан юк!..

**Апамның ял көне**

Апам мәктәптә укый бит!
Ә бүген ял итә ул.
Апам ял иткән көннәрдә
Өебез ялт итә ул!

Әнигә озын көн буе
Без ял оештырабыз:
Өй эчен без апам белән
Икәү җыештырабыз.

Су ташып, газга чәен дә,
Ашын да куябыз без.
Керләр дә юабыз икәү,
Идән дә юабыз без.

Әнием безгә аш салып,
Чәй ясап кына тора.
Әтием, тамагын кырып,
Мыегын гына бора.

**Тамчылар**

Чокыр иде...
Йөри иде
Бәбкәләр үлән өзеп...
Иртән чыксам,

Шул чокырда
Бәбкәләр йөри... йөзеп!

Өйгә кердем, сорау бирдем:
– Әти, ничек күл булган?!
– Сез йоклагач, яңгыр яуды –
Тамчылардан җыелган.

**Кабак**

Тамырлары, суга сусап,
Бетмәсен кибеп кенә.
Кабак үстерәм бакчада
Үзем су сибеп кенә.

Көпшә сабаклары аша
Көн дә су эчте кабак.
Йомшак түтәлдә, тәгәрәп,
Зур булып үсте кабак.

Өйгә алып керәм диеп
Үрелгән идем, юк, әй,
Күтәреп тә булмый үзен –
Эче тулы су бугай!

**Көтү каршылаганда**

Көтү кайта, ихатага
Сарыклар кереп килә.
– Пималарыбыз* кайтты! – ди
Абыем, көлә-көлә.

Әтием әйтте шул миңа:
– Ап-ак кар төшсен, шуннан
Сиңа да пима басарбыз
Ап-ак сарык йоныннан!

Сарыклар артыннан чабып,
Бәрәннәр кереп килә.
– Бияләйләр дә кайтты! – ди
Дәү әти, көлә-көлә.

Дәү әни әйтте шул миңа:
– Ап-ак кар төшсен, шуннан
Бияләй киеп йөрерсең

Ап-ак бәрән йонынннан!

Башын чайкап, «Му-у» да «му-у» дип,
Сыер да кереп килә.
– Сөтлебикә дә кайтты, – ди
Әнием, көлә-көлә.

Сыер сөт бирә – монысын
Энем дә белә инде:
Әнә ул, чынаяк тотып,
Чыгып та килә инде!

**Урамнан үттем атта**

Ат эчерергә барабыз –
Әти атка атланды.
«Син бәләкәй әле», – диде,
Мине алдына алды.

Әти алдына утырып,
Урамнан үттем атта –
Малайлар түгел, кызлары
Көлешеп калды хәтта...

Елга буенда әтием
Сикереп төште җиргә:
«Сызгыр, – диде, – атны кирәк
Сызгырып эчерергә!»

Әй сызгырам... Әти мактый:
«Сызгырсаң, ат эчә ул.
Малай-шалай ат өстендә
Егет булып үсә ул!»

Әти җитәкләде, ә мин
Атланып кайттым атта! –
Кызлар түгел, малайлары
Кызыгып калды хәтта!

**«На-а-а, на-а-а!»**

Энем елый.
Елый-елый,
Идән буйлый мүкәләп.
Атлый да белми шул әле,

Торам үзен бик жәлләп.

«Йөри дә белмисең, – дидем, –
Утыр, – дидем, – аркама.
Атланып утыр – ат булам,
Син куарсың:
«На-а-а, на-а-а, на-а-а!»

Атланды:
«На-а-а, на-а-а!» – дип,
Чәчтән
Тарта, тормый һич жәлләп.
Шаркылдап көлә!..
Мин чабам
Идән буйлап мүкәләп...

**Чаңгылар**

Түбәсенә мендек тауның,
Торабыз аска карап:
Астан сөзәк кебек иде,
Өстән карасаң – харап!

«Әйдә, миннән калма!» – диде,
Абыем төшеп китте.
Абыем менгәнне көтеп,
Аяклар өшеп бетте.

Эх, чаңгыларым курка шул –
Кечкенәләр минеке.
Абыемның чаңгылары
Минеке кадәр ике!

**Утын кистек**

Абыем: «Үстегез, – ди. –
Кил, утын кисегез, – ди. –

Сакланып ышкыгыз, – ди. –
Бик үткен пычкыбыз», – ди.

«Саплары – кулай, – дидем, –
Тарт, энем Юлай», – дидем.

Иртән дә, төш тә кистек,

Ял иткәч, кич тә кистек.

Кистек ике көн тагы,
Бездән уңган кем тагы?

«Житте, күп булды, – дидек, –
Йорт алды тулды!» – дидек...

Без кискән утыннарны
Абый... биш минут ярды!

**Абыем — җиде яшьтә!**

– Мин дә барам! – дидем, абый
Мәктәпкә киенгәч тә.
– Минем яшькә җит әле! – ди,
Абыем – җиде яшьтә!..

# ТАБЫШМАКЛАР

1. Каз кебек су ярата ул,
Йорт кошы ул – каз сыман:
Ни бирсәң дә, соса гына,
Ни бирсәң дә, аз сыман.

2. Хаклы ул ырылдарга да,
Өрергә дә ул хаклы.
Ул булганга – хуҗа тыныч,
Ул булганга – йорт саклы.

3. Мөгрәп көтүгә китә ул,
Мөгрәп кич кайтып керә.
Ел әйләнәсендә безгә
Сөт, катык, каймак бирә.

4. Киткәндә дә, кайтканда да
Гел алдан йөгерәләр.
Сөт тә, катык та бирмиләр,
Алар ит, йон бирәләр.

5. Тавыкларны, чебешләрне
Бигрәк сизгер саклый ул.
Тавыклар йомырка салса,

Куанып кытаклый ул.

6. Мырлап кына йөриләр бит,
Җырлап кына йөриләр.
Яшермәсәң, сөт, каймакны
Урлап кына йөриләр.

7. Ул – ерткыч. Һичкем шаккатмас:
«Бал яратам!» – дисә ул.
...Кирегә укып карагыз:
Кыяклары – аш тәмләткеч,
Тугайларда үсә ул.

8. Ай буе эссе: ник килми
Җил белән, давыл белән? –
Көтәләр калада – кала,
Авылда авыл белән...

9. Кешеләрдә, хайваннарда
Ишетү чарасы ул.
Үзгәрт –
Ян-якка сузылган
Ике кул арасы ул.

10. «Кыт-кыт» дими,
«Га-га» дими,
«Гол-гол»дап кына тора.
Йоннары – күзләр камаша! –
Елкылдап кына тора.

11. Урман, кырда йөгермиләр,
Читлекләрдә яталар.
Кишер генә кимерәләр –
Витамин яраталар.

12. Эре ерткыч кош ул,
Яши
Тауларда, далаларда.
Ауга да йөртәләр аны,
Өйрәтеп алалар да.

13. Кыш көне дә,

Җәй көне дә
Тын гына суза «җырын».
Җәй көне дә,
Кыш көне дә
Өйдә иң суык урын...

14. «Сиксән»дә бар,
«Мең»дә – юк.
«Син»дә дә бар,
«Мин»дә – юк...

15. Ак таш кебек –
Чәйгә салсаң,
Эри дә бетә үзе.
Чәйне бик тәмле дә итә –
Ширбәттәй итә үзе!

16. Тышы – китапныкы кебек,
Китап түгел – сер нидә? –
Барлык битләре дә чиста,
Язылмаган берни дә...

17. Кабы-тышында – исеме,
Җисеме – искитәрлек:
Саксыз кылансаң, бөртеге
Авылны юк итәрлек...

18. Авылда ул чишмә булып
Агып тора урамнан.
Каладамы?
Калада ул
Агып тора... краннан!

19. Чүкеч түгел,
Балта түгел,
Лом түгел,
Түгел көрәк:
Аның белән эшләү өчен
Печән йә салам кирәк!

20. Ныклап кына уйла да яз,
Ал ак кәгазь, ал каләм:

«Дөнья» дип атала,
Тагын
Ничек атала «галәм»?..

21. Мин аңа карасам, ул да
Миңа караган була.
Чәчемне тарасам, ул да
Чәчен тараган була...

22. Ташлары әйләнеп тора
Электрдан, сулардан.
Бодай, арыштан
Ярма, он
Ясатабыз шуңардан.

**Шарадалар***

1. Корты йон әйберен кисә,
Үзе нәрсә була соң?
Өч хәреф кушсаң, чиләкләр
Һәм кәрзиннәр асып йөртү
Җайланмасы: уйла син!

2. Бөртекләре – минераллар,
Була ярма ише ул.
Иҗек куш –
Бик тә туемсыз
Үтә саран кеше ул.

3. Арыганнан соң көч җыю,
Хәл алып тору мәле.
Ике хәреф кушсаң, фәкать
Үлән генә үскән җир ул,
Уйлан әле, бел әле!

4. Җәй буе арба өстери,
Чана тарта, кыш булса.
Вакыт үлчәү берәмлеге –
Бер иҗек тә кушылса...

5. Хуш исле саргылт чәчәкле

Агач бит ул – бел аны:
Бер иҗек кушсаң – урман ул,
Шул агачлар урманы.

6. Язу ул, хәл-әхвәлеңне
Кемгәдер җиткерә ул.
Хәреф кушсаң, «ялгыш» дигән
Яңа мәгънә бирә ул.

7. Күрү органы – беләсең:
Икәү һәрберебездә.
Өч хәреф куш – күрүебез
Сәләтен арттыра торган
Әйбер ул күбебездә.

8. Озын муенлы су кошы –
Агы, аласы була.
Әгәр ике хәреф кушсаң,
Нindидер республиканың
Ул башкаласы була.

9. Өй җылыту һәм ашарга
Пешерү аның «эше».
Иҗек кушсаң, була «шуны»
Чыгара торган кеше.

10. Суыкта калып туңган ул –
Ватып аласы була.
Әгәр ике хәреф кушсаң,
Сыер баласы була.
11. Балыкка охшаш хайван ул
Диңгез-океаннарда.
Әгәр ике хәреф кушсаң,
Төпләнгән басма ул: бел-сә-ә-әң –
Белем тулган аңарга!

12. Музыка коралында ул –
Җеп: ясалма металлдан.
Ике хәреф кушсаң, корал.
Кем әйтер, белеп алдан?..

13. Каты чәч сыман үсенте

Ат койрыгы-ялында.
Дала үләне була ул –
Бер иҗек куш тагын да.

14. Эш эшләү егәре синдә
(Бул җитмештә, биштә син!).
Эт баласы була –
Бары
Ике хәреф өстә син!

15. «Шактый санда», «байтак санда»
(Без белгән сүз, сез белгән!).
Ике хәреф куш – корылма,
Елга аша төзелгән.

16. Картайгач, чәчләргә төшә
(Кем картаймый торган соң?).
Иҗек кушсаң – кием: сана,
Ничәне туздыргансың...

17. Бал кортлары тарафыннан
Чәчәкләрдән җыела.
Хәреф кушсаң,
Кечкенә кыз,
Кечкенә малай була.

Бер иҗек кушсаң...

1. Тәүге иҗек – сүз:
Яну ул,
Ялкын белән бер бит ул.
Иҗек кушсаң,
Су уратып
Алган коры җир бит ул!

2. Тәүге иҗек – сүз:
Шик, курку.
(Кичергәнең бар аны!)
Бер иҗек кушсаң,
Татарда
Әкият каһарманы.

3. Тәүге ике иҗек – терлек:

Көн дә сөт бирә безгә.
Бер иҗек кушсаң,
Сайрар кош:
Яз килә, китә көзгә.

4. Чәчләргә төшә –
Төсен дә
Белмәүче кеше сирәк...
Иҗек кушсаң,
Эш коралы:
Печән чапканда кирәк.

5. Җәядән ату коралы,
Белмисең инде ничек?
Камыр җәя торган таяк,
Кушсаң бер генә иҗек.

**Ул — бер иҗекле сүз-сан...**

1. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Юл капчыгы була,
Әгәр
Тагын бер иҗек кушсаң.

2. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Изү, золым була,
Алга
Бер генә иҗек кушсаң.

3. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Шәһәр ул,
Әгәр дә белеп
Син ике иҗек кушсаң.

4. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
«Бик яхшы» билгесе була,
Тагын бер иҗек кушсаң.

5. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Җылы кием ул,
Алдына
Бер генә хәреф кушсаң.

6. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Ашамлык ул,
Әгәр ике
Иҗекле бер сүз кушсаң.

7. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Бакча гөле ул,
Син ике
Иҗекле бер сүз кушсаң.

8. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Ак мәтрүшкә ул,
Син ике
Иҗекле бер сүз кушсаң.

9. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Авыл ул,
Тукай яшәгән! –
Син ике иҗек кушсаң.

10. Ул – бер иҗекле сүз-сан.
Милли аш була,
Син ике
Иҗекле бер сүз кушсаң.

**Ике иҗек кушсаң...**

1. Ашлык үсә торган мәйдан
(Ашлык үсми чәчмичә!).
Ике иҗек кушсаң,
Бөҗәк,
Аягы әллә ничә...

2. Тәүлекнең бер өлеше ул
(Тәүлекнең якты чагы).
Ике иҗек куш,
Дөньяның
Дүрт ягының бер ягы.

3. Һава агымы ул
(Тагын

Аңлатыйм ничек кенә?).
Бик җиңел холыклы кеше –
Куш ике иҗек кенә!

4. Ява күктән
Уҗымнарга
Бик әйбәт җылы юрган.
Ике иҗек кушсаң,
Кош ул,
Бик җитез оча торган.

5. Икесе бер төптән...
Уйла:
Өч хәрефтән тора ул.
Ике иҗек куш,
Була ул
Г.Тукай туган авыл.

6. Җәлпәк түгәрәк савыт ул
(Әлбәттә, син белгән ул!).
Ике иҗек кушсаң,
Сөлге,
Бизәкләп чигелгән ул!

**Бер хәрефен генә үзгәрт...**

1. Теләгән чакта, теләгән
Җиренә оча ала.
Бер хәрефен генә үзгәрт –
Ел фасылы: юлларыңа
Ак таулар өеп сала.

2. Тәүлекнең күзгә төртсәң дә
Күренмәслек чагы ул.
Бер хәрефен генә үзгәрт –
Тәүлекнең таңнан кичкәчә
Булган чагы тагы ул!

3. «Казан асты» диләр аны:
Утын, күмер ягыла.
Бер хәрефен генә үзгәрт –

Кул белән иген урырга
Уңайлы корал була.

4. Елның яз фасылыннан соң
Килгән вакыт ул: матур!
Бер хәрефен генә үзгәрт –
Эчемлек: эчәсең көнгә
Әллә ничәшәр тапкыр.

5. Суда йөзә (җылы якка
Оча, булса «кыр»ныкы).
Елның алтын фасылы ул –
Бары бер хәрефен генә
Үзгәртеп кенә укы!

6. Иртәнең тәүге өлеше:
Көт тиздән кояш нурын!
Бер хәрефен генә үзгәрт –
Чаңгыларда, чаналарда
Җилдерә торган урын.

**«Кош»-табышмаклар**

1. Аласы да кара анын,
Карасы да чем-кара.
Бер үк исемле үзләре –
Шуны да белми кара!

2. Чут-чут итеп сайрый бит ул,
Сокланып тыңлый кем дә.
Берүзенә ике исем:
Әйт ике исемен дә!

3. Күккә менеп, җырлар җырлый
Кырларга-болыннарга.
Җырлары-моңнары белән
Тиң бит ул былбылларга!

4. Еракларга очалмыйлар,
Очалмый биек алар.
Еракларга – көньякларга
Очканнар – «киек» алар!

5. Оялар әзер – армыйлар,
Талмыйлар оя ясап.
Һәр яз аларга дуслары
Оялар куя ясап!

6. «Шырык-шырык...» –
Ул кычкырса,
Хәбәрләр көтәм никтер.
«Шырык-шырык»,
Хәбәрләрнең
Гел изгеләрен китер!

7. Җәй – урманнар тулы,
Көз, кыш –
Авыл, калалар тулы.
Кеше бар җирдә – тамак тук,
Кеше янында – җылы.

8. Биектә әйләнә:
Җирне
Күзләп кенә оча ул,
Караучысыз чебешләрне,
Караучысыз бәбкәләрне
Эзләп кенә оча ул...

**Табышмакларның җаваплары**

1. Үрдәк. 2. Эт. 3. Сыер. 4. Сарыклар. 5. Әтәч. 6. Песиләр. 7. Аю. Юа. 8. Яңгыр. 9. Колак. Колач. 10. Күркә. 11. Йорт куяннары. 12. Бөркет. 13. Суыткыч. 14. «С» хәрефе. 15. Шакмаклы шикәр. 16. Дәфтәр яки блокнот. 17. Шырпы. 18. Су. 19. Сәнәк. 20. Җиһан. 21. Көзгедәге чагылыш. 22. Тегермән.

**Шарадалар**

1. Көя ® Көянтә. 2. Ком ® Комсыз. 3. Ял ® Ялан. 4. Ат ® Атна. 5. Юкә ® Юкәлек. 6. Хат ® Хата. 7. Күз ® Күзлек. 8. Каз ® Казан. 9. Мич ® Мичче. 10. Боз ® Бозау. 11. Кит ® Китап. 12. Кыл ® Кылыч. 13. Кыл ® Кылган. 14. Көч ® Көчек. 15. Күп ® Күпер. 16. Чал ® Чалбар. 17. Бал ® Бала.

**Бер иҗек кушсаң...**

1. Утрау. 2. Шомбай. 3. Сыерчык. 4. Чалгы. 5. Уклау.

**Ул – бер иҗекле сүз-сан...**

1. Биштәр. 2. Җәбер. 3. Дүртөйле. 4. Бишле. 5. Тун. 6. Өчпочмак. 7. Йөзьяфрак. 8. Меңьяфрак. 9. Өчиле. 10. Бишбармак.

**Ике иҗек кушсаң...**

1. Кыргаяк. 2. Көнчыгыш. Көнбатыш. 3. Җилбәзәк. 4. Карлыгач. 5. Кушлавыч. 6. Тастымал.

**Бер хәрефен генә үзгәрт...**

1. Кош ® кыш. 2. Төн ® көн. 3. Учак ® урак. 4. Җәй ® чәй. 5. Каз ® көз. 6. Таң ® тау.

**«Кош»-табышмаклар**

1. Ала карга. Кара карга. 2. Сандугач. Былбыл. 3. Тургай. 4. Йорт казлары. 5. Сыерчыклар. 6. Саескан. 7. Песнәкләр. 8. Тилгән.

## ЭЧТӘЛЕК


Үзебезнең Салават абый! *Л.Шәех*......3

**Шигырьләр**

Космонавт булам!......5
Барометр......7
Куркак куян......8
Битен юды......9
Серле пычкы, тылсымлы балта.........10
Нигезле дәлил......11
Дәү әнием төшләр күргән......12
Зыя вак балыклар җыя......14
Укырга өйрәнәбез......15
Яшенле яңгырда......16
Мультик......17
Солдат......18
Яз кояшы......20
Календарь......22
Әтәч......23
Болыннарда, аланнарда.........24
Әнием уңган!......26
Карлар эри.........27
Өй рәсеме......28
Серле чәйнек......29
Кулчатыр......30
Күркә......31
Шуклык бәласе......31
Булыштым!......32
Капка ачучы......33
Мәче — нәрсә? Песи — ни?.......33
Яңгыр......34
Искәндәр......35
Зур курчак......36
Телевизор карыйбыз......38
«А-а-а...»......40
Чүкеч......41
Үзем дә белеп торам!......42
Келәт......43
Капкачы......44
Чәчәкле болында......45

Абыем — укучы! ....................................................................46
Урманда ...............................................................................47
Витаминлы кыярлар ............................................................48
Самавыр ...............................................................................49
Велосипедым........................................................................50
Пляжда ..................................................................................52
Сукыр тычкан.......................................................................54
Мунча түбәсен ябабыз ........................................................55
Укчы .....................................................................................56
Апамның ял көне .................................................................56
Тамчылар ..............................................................................58
Кабак ....................................................................................59
Көтү каршылаганда .............................................................60
Урамнан үттем атта .............................................................62
«На-а-а, на-а-а!»...................................................................64
Чаңгылар...............................................................................65
Утын кистек .........................................................................66
Абыем — җиде яшьтә! ........................................................67

**Табышмаклар**

Табышмаклар .......................................................................68
Шарадалар ............................................................................76
Бер иҗек кушсаң...................................................................81
Ул бер иҗекле сүз-сан..........................................................83
Ике иҗек кушсаң... ...............................................................86
Бер хәрефен генә үзгәрт.......................................................88
«Кош»-табышмаклар............................................................90

Табышмакларның җаваплары ..............................................93

Литературно-художественное издание
Для детей младшего школьного возраста

**Рахматулла** Салават
(**Рахматуллин** Салават Ибрагимович)

БУДУ КОСМОНАВТОМ!

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Рәхмәтулла** Салават
(**Рәхмәтуллин** Салават Ибраһим улы)

КОСМОНАВТ БУЛАМ!

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.02.2010. Форматы 60г90 1/16.
Басма табагы 6,0. Тиражы 2000 д. Заказ В-694.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.